**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР

07.12. 2023ел N 110

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлегендә
бюджет процессы турындагы
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96_6 һәм 220_1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының үтәлеш үзенчәлекләрен билгеләү турында " 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы: КАРАР КЫЛДЫ

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау турында" 2022 елның 22 мартындагы 51 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр нигезләмәнең 36 статьясының 3 пункты һәм 37 статьясының 3 пункты гамәлдә булуын туктатып торырга.

2. Әлеге карарны Татар Чаллысы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына урнаштырып игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында " Татар Чаллысы авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы рәисе Т.П. Кузнецова.